

Без ел саен “Масленица”ны зурлап бәйрәм итәбез. Һәрвакыттагыча, уен-колке, жыр-биюләр белән vтә. Балалар очен торле аттракционнар эшли. Республиканын ин талантлы фольклор коллективлары чыгышлары белән халыкнын кvнелен яулый. Әлеге бәйрәмне бергәләп vткәргән тосле, татар милләтле халыкынын да бәйрәмнәрендә рус, мордва һәм теләсә кайсы милләт вәкиле рәхәтләнеп ял итә. Керәшеннәребездә “Май чабу” дип аталган “Белен бәйрәм”е бар. Кыскасы, сvзебез Атюрьево авылынын vзәк мәйданында «Белен коне» дигән республика гастрономия фестивале турында. Бу нәкъ менә мордва халкынын vзенчәлекле мәдәнияте белән якыннанрак танышырга момкин булган вакыйга. Татарларыбыз белен бәйрәмнәрендә генә катнашып калмый, бәлеш бәйрәмнәре дә vткәрә. Еш кына Рузаевка районы Татар Пешләсендә бәлешкә багышланган чаралар, “Бәлеш” дип исемләнгән балалар очен чаралар vтә.
Татар халкынын аш-суга унганлыгы гасырлар белән vлчәнә. Белен рецептларынын да торлесе – калыны, нечкәсе, коймаклары һәм башка тәмлушкалары кvп. Татарлар, торле беленнәре белән бергә, мукшыларнын калын белен-пачатны да ундыралар. Бәйрәмдә оста пәрәмәчләрне, бәлешләрне, беленнәрне пешереп сыйлаучылар да, татар жыр-биюләрен дә Саида Абдул-Ракип кызы Байбекова, Роза Сәет кызы Макарова, Римма Шамиль кызы Теркулова, Раиса Васильевна Чудина Атюрьево районы халкына, килгән кунакларга тәгъдим иткәннәр: рәхәтләнеп кvнел ачканнар. Ин оста белен пешерvче тавыш санын санап билгеләгәннәр.

*(Фото: С.Байбекова)*